МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ___700/о_______

П Р И К А З

Б О Е Р Ы К

«__02___»______06________2025__

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-32 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иштирәк авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү турында» 2024 елның 5 апрелендәге 70/о номерлы боерыгы, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе утырышының 2025 елның 7 апрелендәге 30 номерлы беркетмәсе нигезендә, 2025 елның 19 мартында уздырылган гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кушымтада бирелә торган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсенең Кама агломерациясен үстерү бүлегенә (В.В.Бельскийга) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь

хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны;

«Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен файдаланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең координаталары исемлеге булган территориаль зоналар чикләре турындагы белешмәләрне әлеге боерык үз көченә кергән көннән алып биш эш көне эчендә электрон рәвештә җибәрүне;

әлеге боерыкны ул басылып чыккан көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Отдел контроля исполнения документов

Министр урынбасары В.Н.Кудряшев

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 02.06.2025 ел, № 700/о боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре**

**ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ДОКУМЕНТЛАРЫ СОСТАВЫ**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре документлары составына түбәндәгеләр керә:

Кереш

1. Текст материаллары:

- 1 том. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе;

- 2 том. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары. Шәһәр төзелеше регламентлары.

2. Кушымта:

- Территориаль зоналарның чикләре турында белешмәләр.

# ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

1 том.

ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕНӘ
ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ

2025 ел

# ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ........................................................................................................................8
I БҮЛЕК. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР........................................................................................9
1 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен кертү нигезләре, билгеләнеше һәм составы.........................................................................................................................................9
2 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш турында мәгълүматның ачык һәм аңлаешлы булуы....9
**II БҮЛЕК. Вәкаләтле органнар тарафыннан җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу турында нигезләмәләр**..................................................................................................................11
5 статья. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләре...........................................................................11
6 статья. Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе...........................................................................................................................11
7 статья. Элек барлыкка килгән хокукларга кагылышлы гомуми нигезләмәләр........................12
8 статья. Территориаль зоналар........................................................................................................12
9 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары һәм аларны куллану....................................................13
**III БҮЛЕК. Физик һәм юридик затлар тарафыннан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү турында нигезләмәләр**16
10 статья. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү тәртибе...............................................................................................16
11 статья. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү тәртибе.....................................................................................17
12 статья. Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү тәртибе..................................................................17
**IV БҮЛЕК. Вәкаләтле органнар тарафыннан территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында нигезләмәләр**.............................................................................................................18
13 статья. Территорияне планлаштыру документациясенә гомуми таләпләр.............................18
**14 статья. Территорияне планлаштыру буенча документация төрләре**.................................19
**V БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча гавами тыңлаулар уздыру турында нигезләмә**..........................................................................................................................21
15 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча гомуми нигезләмәләр........................................................................................21
**VI БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында нигезләмәләр**.....................................................................................................................22
16 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе...............22
**VII БҮЛЕК. Җирдән файдалануның һәм төзелешнең башка мәсьәләләрен җайга салу турында нигезләмәләр**..................................................................................................................................23
17 статья. Территориаль зоналар чикләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү.....................................................................................................................23
18 статья. Территорияне комплекслы үстерү...................................................................................23
VIII БҮЛЕК. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары.................................................................29
19 статья. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар..................................29
20 статья. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар..................................................................................................................32
**21 статья. Территориаль зоналарның чикләре турында белешмәләр (китерелми)**.............32
IX БҮЛЕК. ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ РЕГЛАМЕНТЛАРЫ.........................................................................33
22 статья. Шәһәр төзелеше регламенты составы...............................................................................33
23 статья. Территориаль зоналарның шәһәр төзелеше регламентлары.........................................34
**23.1. Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре**....................................................................34
**23.2. Индивидуаль торак төзелеше зоналарының шәһәр төзелеше регламенты (Ж1)**.............35
**23.3. Азкатлы торак төзелеше зоналарының шәһәр төзелеше регламенты (Ж2)**......................39
**23.4. Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зоналарның шәһәр төзелеше регламенты (ОД)**....43
**23.5. Транспорт инфраструктурасы зоналарының шәһәр төзелеше регламенты (Т)**.............47

**23.6. Инженерлык инфраструктурасы зоналарының шәһәр төзелеше регламенты (И)..........49**
**23.7. III класслы хәвефлелектәге җитештерү һәм склад объектлары зоналарының шәһәр төзелеше регламенты (П2.1)..........50**
**23.8. Коммуналь-склад объектлары зоналарының шәһәр төзелеше регламенты (КС)..........52**
**23.9. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зоналарының шәһәр төзелеше регламенты (СХ2)..........54**
**23.10. Рекреацион билгеләнештәге зоналарның шәһәр төзелеше регламенты (Р2)..........56**
**23.11. Зиратларны урнаштыру зоналарының шәһәр төзелеше регламенты (СН1)..........57**
**23.12. Оборона һәм иминлек объектлары зоналарының шәһәр төзелеше регламенты (ОБ). .59**
24 статья. Шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый торган җирләр..........60
25 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнмәгән җирләр..........61
X БҮЛЕК. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләүләр..........62
26 статья. Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләүләр..........62
**26.1. Гомуми нигезләмәләр..........62**
**26.2. Эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналары..........63**
**26.3. Су саклау зоналары, җир өсте су объектларының яр буе саклык полосалары..........64**
**26.4. Электр энергетикасы объектларының саклау зоналары..........66**
**26.5. Үткәргечләрнең саклау зоналары..........68**
**26.6. Элемтә линияләренең һәм корылмаларының саклык зоналары..........70**
**26.7. Санитар-саклык зоналары..........72**
**26.8. Файдалы казылмалар ятмалары, җир асты байлыклары кишәрлекләре, тау токымнары..........72**
**26.9. Магистраль яисә технологик торбаүткәргечләрнең минималь ераклык зоналары..........73**
**26.10. Аэродром яны территорияләре..........75**
XI БҮЛЕК. Территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең минималь рөхсәт ителә торган дәрәҗәсенең исәпләмә күрсәткечләре һәм мондый объектларның халык өчен территориаль яктан файдалана алуының максималь рөхсәт ителә торган дәрәҗәсенең исәпләмә күрсәткечләре..........76

КЕРЕШ

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Урман кодексы, Россия Федерациясе Су кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2020 елның 13 мартындагы 279 номерлы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы һәм «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә әзерләнгән шәһәр төзелешен зоналаштыру документы.

Кагыйдәләрне әзерләгәндә шулай ук Тукай муниципаль районының һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актлары, муниципаль

берәмлекнең социаль-икътисадый һәм шәһәр төзелеше үсешенең төп юнәлешләрен билгеләүче башка документлар нигезләмәләре исәпкә алына.

Әлеге Кагыйдәләр территориаль зоналарны, шәһәр төзелеше регламентларын, әлеге Кагыйдәләрне куллану һәм аларга законнар, җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары нигезендә үзгәрешләр кертү тәртибен билгели, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясеннән муниципаль берәмлек территориясен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне саклау, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен нәтиҗәле файдалану шартларын, шул исәптән җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның иң нәтиҗәле төрләрен сайлау мөмкинлеге бирү юлы белән инвестицияләр җәлеп итү өчен дә шартлар тудыралар.

## I БҮЛЕК. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен кертү нигезләре, билгеләнеше һәм составы

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре республика башкарма хакимият органының норматив хокукый акты статусына ия. Әлеге Кагыйдәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә (алга таба – муниципаль берәмлек, җирлек) җирдән файдалануны һәм төзелешләрне җайга салу системасын кертәләр.

2. Әлеге кагыйдәләр түбәндәге максатларда эшләнгән:

1) муниципаль берәмлек территориясен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау өчен шартлар тудыру;

2) муниципаль берәмлек территориясен планлаштыру өчен шартлар тудыру;

3) физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокукларына ия булучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү;

4) инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның иң нәтиҗәле төрләрен сайлау мөмкинлеге бирү юлы белән дә.

3. Әлеге кагыйдәләр түбәндәгеләр белән берлектә кулланыла:

техник регламентлар белән (алар билгеләнгән тәртиптә үз көченә кергәнче – «Техник җайга салу турында» 2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы федераль законга һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына каршы килми торган өлешендә норматив техник документлар белән);

Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән;

шәһәр төзелешен проектлау нормативлары белән;

- җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу мәсьәләләре буенча «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының норматив хокукый актлары белән.

4. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, җайга салучы һәм контрольдә тотучы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар, вазыйфаи затлар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

2 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш турында мәгълүматның ачык һәм аңлаешлы булуы

1. Әлеге Кагыйдәләр, үз составына керүче барлык картографик һәм башка документларны да кертеп, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең барлык физик һәм юридик затлары, шулай ук вазыйфаи затлары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен ачык булып тора.
2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) әлеге Кагыйдәләр белән танышу мөмкинлеген тәэмин итә, түбәндәге юллар белән:
- республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны, шулай ук Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;
- Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән вакытта Министрлык тарафыннан урнаштыруны.

## II БҮЛЕК. Вәкаләтле органнар тарафыннан җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу турында нигезләмәләр

5 статья. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләре

1. Татарстан Республикасы Тукай районы муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсе вәкиллекле органы – Татарстан Республикасы Тукай районы советы вәкаләтләре:
1.1 җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тота торган проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары (алга таба әлеге пунктта – проектлар) буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибен, гавами тыңлаулар/иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыны, гавами тыңлаулар/иҗтимагый фикер алышулар үткәрү срокларын, рәсми сайтны һәм (яисә) мәгълүмат системаларын, гавами тыңлаулар/иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрләр урнаштырыла торган мәгълүмат стендларына карата таләпләрне, гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итү формаларын, гавами тыңлауларны әзерләү тәртибен һәм беркетмә рәвешләрен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү тәртибен һәм формасын, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен үткәрү тәртибен, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләргә консультация бирү тәртибен билгеләү.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге башлыгы – Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башлыгы вәкаләтләре:
2.1 җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында карар кабул итү.
Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлүгә бәйле рәвештә «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән җирле үзидарә органнары вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 06.07.2005 ел, №313 карары нигезендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6 статья. Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе

1. Татарстан Республикасының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - комиссия) Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне күздә тотучы проектны әзерләү максатларында төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.
2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы һәм «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе турында» 2024 елның 5 мартындагы 35/о номерлы боерыгына таяна.
3. Комиссия составы һәм аның функцияләү тәртибе Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе турында» 2024 елның 5 мартындагы 35/о номерлы боерыгы белән расланды.
5. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан раслана.
6. Комиссия эше турындагы мәгълүмат барлык кызыксынган затлар өчен дә ачык.

7 статья. Элек барлыкка килгән хокукларга кагылышлы гомуми нигезләмәләр

1. Җир кишәрлеге яисә капиталь төзелеш объекты әлеге Кагыйдәләргә туры килми, әгәр:
- аларны рөхсәт ителгән файдалану төрләре тиешле территориаль зона өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төрләре исемлегенә кермәсә;
- аларның күләмнәре һәм параметрлары тиешле территориаль зонаның шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән чик күрсәткечләргә туры килмәсә.
2. Рөхсәт ителгән файдалану төрләре, иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) зурлыклары һәм иң чик параметрлары шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган җир кишәрлекләре яисә капиталь төзелеш объектлары аларны шәһәр төзелеше регламентына туры китерү срогын билгеләмичә файдаланырга мөмкиннәр, мондый җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану кеше гомере яисә сәламәтлеге, әйләнә-тирә мохит, мәдәни мирас объектлары өчен куркыныч булган очраклардан тыш.
3. Чик (минималь һәм (яисә) максималь) зурлыклары һәм чик параметрлары шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү бары тик мондый объектларны шәһәр төзелеше регламентына туры китерү юлы белән яисә аларның рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең чик параметрларына туры килмәвен киметү юлы белән генә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү аларны шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләренә туры китерү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.
4. Рөхсәт ителгән файдалану төрләре, иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) зурлыклары һәм иң чик параметрлары шәһәр төзелеше регламентына туры килмәгән җир кишәрлекләреннән яисә капиталь төзелеш объектларыннан файдалану дәвам итсә һәм кеше гомере яисә сәламәтлеге өчен, әйләнә-тирә мохит, мәдәни мирас объектлары өчен куркыныч тудырган очракта, федераль законнар нигезендә мондый җир кишәрлекләреннән һәм объектлардан файдалануга тыю салынырга мөмкин.

8 статья. Территориаль зоналар

1. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләгәндә территориаль зоналарның чикләре түбәндәгеләрне исәпкә алып билгеләнә:
- бер территориаль зона чикләрендә җир кишәрлекләреннән гамәлдәге һәм планлаштырылган файдалануның төрле төрләрен берләштерү мөмкинлекләрен;
- җирлекнең генераль планында (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән очрактан тыш), муниципаль районны территориаль

планлаштыру схемасында билгеләнгән функциональ зоналар һәм аларның планлаштырыла торган үсеше параметрларын;
- Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән территориаль зоналарны;
- территориянең гамәлдәге планлаштырылуын һәм җирдән файдалануны;
- төрле категориядәге җир чикләренә планлаштырылган үзгәрешләрне;
- чиктәш җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларына зыян китерү мөмкинлеген булдырмауны;
- федераль әһәмияттәге тарихи җирлекнең тарихи-мәдәни терәк планын яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең тарихи-мәдәни терәк планын.
2. Территориаль зоналарның чикләре түбәндәгеләр буенча билгеләнә ала:
- капма-каршы юнәлешләрдәге транспорт агымнарын аерып торучы магистральләр, урамнар, машина юллары линияләре;
- кызыл линияләр;
- җир кишәрлекләре чикләре;
- муниципаль берәмлекләр чикләрендәге торак пунктлар чикләренә;
- муниципаль берәмлекләр чикләренә;
- табигать объектларының табигый чикләренә;
- башка чикләргә.
3. Территориаль зоналарның чикләре муниципаль берәмлекләр, торак пунктлар, җир кишәрлекләре чикләрен (Россия Федерациясе Җир кодексында яисә башка федераль законда каралган очракларда, чикләре территориаль зоналар чикләрен кисеп үтәргә мөмкин булган җир кишәрлегеннән тыш) кисеп үтә алмый. Территориаль зоналар чикләрен территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләре, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләре белән кисештерү рөхсәт ителә.
4. Территориаль зоналарның чикләре, чикләре Россия Федерациясе Җир кодексында һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очракларда, территориаль зоналар чикләрен кисеп үтәргә мөмкин булган җир кишәрлегеннән тыш, һәр җир кишәрлегенең бары тик бер территориаль зонага каравы таләбенә җавап бирергә тиеш.
5. Һәр территориаль зона өчен әлеге Кагыйдәләр белән шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә.

## 9 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары һәм аларны куллану

1. Шәһәр төзелеше регламентында җир кишәрлекләренең, шулай ук җир кишәрлекләре өстендә һәм астында булган һәм аларны төзү һәм капиталь төзелеш объектларын алга таба эксплуатацияләү процессында кулланыла торган барлык нәрсәләрнең хокукый режимы билгеләнә.
2. Шәһәр төзелеше регламентлары түбәндәгеләрне исәпкә алып билгеләнә:
- территориаль зона чикләрендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан фактта файдалану;
- җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын гамәлдә булган һәм планлаштырылган файдалануның төрле төрләрен бер территориаль зона чикләрендә берләштерү мөмкинлекләре;
- муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру документларында билгеләнгән функциональ зоналары һәм аларның планлаштырыла торган үсеш характеристикалары;
- территориаль зоналарның төрләре;
- мәдәни мирас объектларын, махсус сакланылучы табигать территорияләрен, башка табигать объектларын саклау таләпләре.
3. Шәһәр төзелеше регламентында тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата түбәндәгеләр күрсәтелә:

- җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре;
- җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрлары;
- җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган чикләүләр;
- аңа карата шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә торган территориаль зона чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру күздә тотылган очракта, территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәпләмә күрсәткечләре һәм күрсәтелгән объектларның халык өчен территориядән файдалана алуының мөмкин булган максималь дәрәҗәсенең исәпләмә күрсәткечләре.

4. Шәһәр төзелеше регламентының гамәлдә булуы шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында күрсәтелгән территориаль зона чикләре чикләрендә урнашкан барлык җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына бертигез дәрәҗәдә кагыла.

5. Шәһәр төзелеше регламентының гамәлдә булуы түбәндәге җир кишәрлекләренә кагылмый:
- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән һәйкәлләр һәм ансамбльләр территорияләре чикләрендә, шулай ук ачыкланган мәдәни мирас объектлары булган һәм аларны тоту режимы, реставрацияләү, консервацияләү, торгызу, ремонтлау һәм җайлаштыру параметрлары турында карарлар мәдәни мирас объектларын саклау турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кабул ителә торган һәйкәлләр яки ансамбльләр территорияләре чикләрендә;
- гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрендә;
- линия объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән һәм (яисә) линия объектлары биләгән;
- файдалы казылмалар чыгару өчен бирелгән.

6. Тарихи җирлекләр, истәлекле урыннар территорияләренә, территорияләрдән файдалануның аерым шартлары булган зоналарга карата шәһәр төзелеше регламентлары Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

7. Шәһәр төзелеше регламентлары түбәндәгеләр өчен билгеләнми:
- урман фонды җирләре;
- өске сулар белән капланган җирләр;
- запастагы җирләр;
- махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләре;
- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составындагы авыл хуҗалыгы җирләре;
- махсус икътисадый зоналар һәм алгарышлы үсеш территорияләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре.

8. Шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый торган яисә шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җир кишәрлекләреннән файдалану федераль законнар нигезендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтле башкарма органнары яисә вәкаләтле җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

Урман фонды җирләре составындагы җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән, махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендә урнашкан җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән (махсус сакланылучы табигать территорияләре составына кертелгән торак пунктлар территорияләреннән тыш) файдалану тиешенчә урман хуҗалыгы регламенты, урман законнары, махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы законнар нигезендә махсус сакланылучы табигать территориясе турындагы нигезләмә нигезендә билгеләнә.

## III БҮЛЕК. Физик һәм юридик затлар тарафыннан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү турында нигезләмәләр

10 статья. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү тәртибе

1. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы нигезендә билгеләнә.
2. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану түбәндәге төрләрдә булырга мөмкин:
1) рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре;
2) шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрләре;
3) рөхсәт ителгән файдалануның рөхсәт ителгән төп төрләренә һәм шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрләренә карата өстәмә буларак кына рөхсәт ителә торган һәм алар белән бергә гамәлгә ашырыла торган ярдәмче төрләре.
3. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның икенче төренә үзгәртү, техник регламентлар таләпләре үтәлгән очракта, шәһәр төзелеше регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.
4. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның төп һәм ярдәмче төрләре, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән, дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән тыш, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан хокук ияләре тарафыннан өстәмә рөхсәтсез һәм килештерүсез мөстәкыйль сайлана.
5. Шәһәр төзелеше регламентлары гамәлдә булмаган яисә шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнмәгән җирләрдә урнашкан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен үзгәртү турындагы карарлар федераль законнар нигезендә кабул ителә.
6. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану төрен үзгәртү җирләрнең максатчан билгеләнешен һәм категориясен үтәгәндә гамәлгә ашырыла.
7. Шәһәр төзелеше регламенты нигезендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану төрен үзгәртү хокукка ия булучылар тарафыннан рөхсәт ителми:
1) мондый кишәрлектә капиталь төзелеш объектын төзүгә бәйле рөхсәт ителгән файдалану төрләренә төзелешкә бәйле булмаган максатлар өчен бирелгән җир кишәрлегенә карата;
2) мондый җир кишәрлегендә файдалануның төп яисә шартлы рөхсәт ителгән төре булган капиталь төзелеш объекты булмаганда рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төренә карата;
3) шәһәр төзелеше регламентының гамәлдә булуы кагылмый торган җир кишәрлегенә карата;
4) шәһәр төзелеше регламенты билгеләнмәгән җир кишәрлегенә карата.
8. Җир кишәрлекләреннән файдалануның төп яисә шартлы рөхсәт ителгән төре мондый җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән файдалануның тиешле төре турында белешмәләр Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына (алга таба – КМБДР) кертелгән көннән сайланган дип санала. КМБДР җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре турында белешмәләр кертү таләп ителми.
9. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер үк төрләре ярдәмче һәм шартлы рөхсәт ителгән файдалану төрләре исемлегендә бер үк вакытта булырга мөмкин. Мондый очракларда рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төре территориаль зонаның шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалануның төп төре белән бергә файдаланылса билгеләнә. Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төре төп буларак билгеләнү планлаштырылган

очракларда кулланыла (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясында каралган тәртиптә файдалануның мондый төренә рөхсәт алу шарты белән).

11 статья. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү тәртибе

1. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт тиешле дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибендә бирелә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә.

12 статья. Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү тәртибе

1. Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт тиешле дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибендә бирелә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә.
2. Капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгәндә күрсәтелгән капиталь төзелеш объектының төзелеш мәйданы үзгәрмәгән очракта, җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенешләрдән тайпылуга рөхсәт бирү таләп ителми.

## IV БҮЛЕК. Вәкаләтле органнар тарафыннан территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында нигезләмәләр

13 статья. Территорияне планлаштыру документациясенә гомуми таләпләр

1. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын аерып алу, җир кишәрлекләренең чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналарының чикләрен билгеләү максатларында гамәлгә ашырыла.
Территорияне планлаштыру документларын әзерләү, әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 102 өлешендә башкасы каралмаган булса, территориаль планлаштыру документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (линия объектларын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру документларын әзерләүдән тыш), урман хуҗалыгы регламенты, коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программалары нигезендә махсус сакланылучы табигать территориясе турында нигезләмә, транспорт инфраструктурасын комплексл\u044b үстерү программалары, социаль инфраструктураны комплекслы үстерү программалары, шәһәр төзелешен проектлау нормативлары, юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемалары, «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән юл хәрәкәтен оештыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү таләпләре, техник регламентлар, кагыйдәләр җыелмалары таләпләре нигезендә; инженерлык эзләнүләре материалларын һәм нәтиҗәләрен, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен, ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен, территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.
2. Капиталь төзелеш объектын урнаштыру максатларында территорияне планлаштыру документларын әзерләү түбәндәге очракларда мәҗбүри була:
- федераль, региональ яисә җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектын урнаштыруга бәйле рәвештә дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен тартып алу зарурлыгына бәйле рәвештә;
- кызыл линияләрне билгеләү, үзгәртү яисә бетерү кирәк булса;
- җир законнары нигезендә җир кишәрлекләрен төзү территорияне ызанлау проекты нигезендә генә гамәлгә ашырыла алган очракта, җир кишәрлекләрен барлыкка китерү зарурлыгы булса;
- капиталь төзелеш объектын урнаштыру уртак чиге булган ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлекләр территорияләрендә планлаштырылса (мондый капиталь төзелеш объектын урнаштыруны дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган һәм мондый капиталь төзелеш объектын урнаштыру өчен дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен бирү һәм сервитутлар билгеләү таләп ителмәгән очрактан тыш);
- линия объектын төзү, реконструкцияләү планлаштырылса (линия объектын дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә урнаштыру планлаштырылган һәм мондый линия объектын урнаштыру өчен дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен бирү һәм сервитутлар билгеләү таләп ителмәгән очрактан тыш). Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документация әзерләү таләп ителми торган башка очраклар билгеләнергә мөмкин;
- линия объекты булмаган капиталь төзелеш объектын һәм аның эшләвен тәэмин итү өчен кирәкле капиталь төзелеш объектларын махсус сакланылучы табигать территориясе чикләрендә яисә урман фонды җирләре чикләрендә урнаштыру планлаштырылса;

- территорияне комплекслы үстерү планлаштырылса;
- «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү планлаштырылса;
3. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү планлаштыру структурасының җирдән файдалану һәм территориаль зоналарны төзү кагыйдәләрендә билгеләнгән һәм (яисә) муниципаль районнарны территориаль планлаштыру, функциональ зоналар схемаларында, җирлекләрнең, муниципаль округларның генераль планнарында, территорияне комплекслы үстерү каралган территорияләрдә билгеләнгән бер яисә берничә чиктәш элементларының территориясен планлаштыру проектында бүлеп бирелә торган өлешләренә карата гамәлгә ашырыла.
4. Территорияне планлаштыру документларының гомуми таләпләре, әзерләү һәм раслау, шулай ук җирлек территориясенә карата территорияне планлаштыру документларын әзерләү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы һәм «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.
5. Территорияне планлаштыру документларын әзерләүне Министрлык тәэмин итә.
6. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 27.12.2023 ел, № 3134-р күрсәтмәсе белән расланган Татарстан Республикасында территорияне планлаштыру проектларын формалаштыруга һәм әзерләүгә методик таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 14 статья. Территорияне планлаштыру буенча документация төрләре

1. Территорияне планлаштыру буенча документация төрләре булып түбәндәгеләр тора:
- территорияне планлаштыру проекты;
- территорияне ызанлау проекты.
2. Территорияне планлаштыру проектларын әзерләү планлаштыру структурасы элементларын аерып чыгару, гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү, территорияне планлаштырып үстерү характеристикаларын һәм чиратлыгын билгеләү өчен гамәлгә ашырыла.
3. Территорияне ызанлау проектын әзерләү планлаштыру структурасының бер яисә берничә чиктәш элементы чикләрендә, территориаль зонаның җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә билгеләнгән чикләрендә һәм (яисә) муниципаль районны территориаль планлаштыру, функциональ зона схемасында, җирлекнең генераль планында, территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлегендә каралган территориянең билгеләнгән чикләрендә урнашкан территориягә карата гамәлгә ашырыла.
4. Территорияне ызанлау проектын әзерләү түбәндәгеләр өчен гамәлгә ашырыла:
- барлыкка килә торган һәм үзгәртелә торган җир кишәрлекләренең чикләре урнашу урынын билгеләү;
- чикләрендә капиталь төзелешнең яңа объектларын урнаштыру планлаштырылмый торган төзелгән территорияләр өчен, шулай ук, мондый билгеләүләр, үзгәртүләр, гамәлдән чыгару бары тик гомуми файдаланудагы территория чикләрен үзгәртүгә генә китергән очракта, территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлегендә күздә тотылмаган территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлеген барлыкка китерүгә һәм (яисә) үзгәртүгә бәйле рәвештә кызыл линияләрне билгеләү, үзгәртү, туктату өчен.

5. Территорияне ызанлау проекты расланырга тиешле төп өлештән һәм әлеге проектны нигезләү материалларыннан гыйбарәт.

6. Территорияне ызанлау проектларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын әзерләү өчен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә мондый инженер эзләнүләрен башкару таләп ителгән очракларда, инженер эзләнүләре материалларын һәм нәтиҗәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла. Территорияне ызанлау проектын әзерләү максатларында әлеге территорияне планлаштыру проектын әзерләү өчен алынган инженерлык эзләнүләре материалларыннан һәм нәтиҗәләреннән аларны үтәгән көннән алып иң күбе биш ел дәвамында файдалану рөхсәт ителә.

7. Территорияне ызанлау проектын әзерләгәндә төзелә торган һәм (яисә) үзгәртелә торган җир кишәрлекләренең чикләре урнашу урынын билгеләү шәһәр төзелеше регламентлары һәм эшчәнлекнең конкрет төрләре өчен җир кишәрлекләрен бүлеп бирү нормалары, барлыкка килә торган һәм (яисә) үзгәртелә торган җир кишәрлекләренә карата федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында, техник регламентларда, кагыйдәләр җыелмаларында билгеләнгән башка таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Территорияне ызанлау проектын эшләү чикләрендә җир кишәрлекләре барлыкка килү каралган территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең урнашуының расланган схемасы нигезендә гамәлдә булу срогы тәмамланмаган территориягә карата гамәлгә ашырылган очракта, мондый территорияне ызанлау проектында җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны әлеге схемада төзелүе каралган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына туры килергә тиеш.

9. Тарихи җирлек территориясенә карата әзерләнгән территорияне ызанлау проектында сакланышын тәэмин итү Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау турындагы законнарда каралган планлаштыру структурасы элементлары исәпкә алына.

10. Территорияне планлаштыру проекты белән расланган планлаштыру структурасы элементы яисә элементлары чикләрендә урнашкан территорияне ызанлау проектын аерым документ рәвешендә әзерләгән очракта, территория чикләрендә урнашкан һәм (яисә) территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлегендә күздә тотылмаган җир кишәрлеге барлыкка килүгә һәм (яисә) үзгәрүгә бәйле рәвештә кызыл линияләрне билгеләү, үзгәртү, бетерү өчен территорияне ызанлау проектын әзерләү очрагыннан тыш, кызыл линияләрне шушы рәвешле билгеләү, үзгәртү гомуми файдаланудагы территория чикләрен үзгәртүгә китергән шарт белән.

11. Территорияне планлаштыру документларына карата гомуми таләпләр, эчтәлек, әзерләү һәм раслау тәртибе Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы һәм «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

## V БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча гавами тыңлаулар уздыру турында нигезләмә

15 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча гомуми нигезләмәләр

Гавами тыңлаулар түбәндәге мәсьәләләр буенча яшәешнең уңайлы шартларына кеше хокукын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатларында үткәрелә:
1) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларына, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында;
2) территорияне планлаштыру проектларына, территорияләрне планлаштыру проектларына үзгәрешләр кертүгә;
3) территорияне ызанлау проектларына, территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертүгә;
4) җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына;
5) капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына.
2. Гавами тыңлаулар эш һәм ял көннәренә билгеләнергә мөмкин. Рәсми бәйрәм көннәрендә гавами тыңлаулар уздырылмый.
3. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре киңәш итү характерында була.
4. Проектлар буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе, гавами тыңлауларны оештыручы, гавами тыңлауларны уздыру срогы, рәсми сайт һәм (яисә) мәгълүмат системалары, гавами тыңлаулар башлану турында хәбәрләр урнаштырыла торган мәгълүмат стендларына таләпләр, гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү рәвеше, гавами тыңлауларны әзерләү тәртибе һәм беркетмә рәвеше, гавами тыңлауларны әзерләү тәртибе һәм нәтиҗәләре турында бәяләмә формасы, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен үткәрү тәртибе, шулай ук гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләргә консультация бирү тәртибе Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы һәм (яисә) җирле үзидарәнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

## VI БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында нигезләмәләр

16 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе

1. Әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү, әлеге статья үзенчәлекләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Территориаль зоналар кагыйдәләрдә билгеләнмәгән торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан җир кишәрлекләрендә төзелеш ниятләре барлыкка килгән очракта, мондый җир кишәрлекләренең хокукый режимы тиешле территориаль зона билгеләү өлешендә Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү юлы белән билгеләнә.

## VII БҮЛЕК. Җирдән файдаланунының һәм төзелешнең башка мәсьәләләрен җайга салу турында нигезләмәләр

17 статья. Территориаль зоналар чикләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү

1. Территориаль зоналар чикләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү кагыйдәләре «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның 32, 34 статьялары нигезләмәләре белән билгеләнә.
2. Әлеге Кагыйдәләр белән территориаль зоналар, шул исәптән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы җир кишәрлекләренең, торак пунктларның яисә муниципаль берәмлекләрнең чикләре урнашу урынын билгеләүдәге хаталарны исәпкә алып билгеләнә. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында белешмәләре булмаган торак пунктларның чикләренә карата аларның чикләрен билгеләүдәге хаталар исәпкә алынмый.

18 статья. Территорияне комплекслы үстерү

Территорияне комплекслы үстерү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү проектларын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 елның 24 сентябрендәге 913 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ ИШТЕРЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ. ТЕРРИТОРИАЛЬНЫЕ ЗОНЫ

М 1:10000



